Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче 2нче балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе



# Бергәләп уйнап алыйк!

дидактик уеннар һәм кулламалар җыентыгы

Теләче, 2022

# Кереш

Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартларында да уен аша тәрбия һәм белем бирүгә нык игътибар бирелә.Уен технологияләре куллану балаларның иҗат мөмкинлеген ачарга, мөстәкыйллекләре арттырга,оештыру сәләтләрен үстерүгә ярдәм итә.

Шулай ук Татарстан республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән уку-укыту әсбаплары, укыту методик комплектлар, татарча мульфильмнар, электрон ярдәмлекләр, аудио-һәм видеоматериаллар куллану да уен нәтиҗәлеген арттырырга ярдәм итә туган (татар) теленә һәм рус телләренә өйрәтү буенча УМК белән эшчәнлек оештырганда дидактик уеннар куллануның әһәмияте бик зур. Бу уеннарны шулай ук тәрбиячеләр дә төркемнәрдә өйрәнгән материалны ныгыту өчен куллана алалар. Дидактик уеннар баланың сөйләм телен, сүз байлыгын, хәтерен, иҗади фикер йөртүен, игътибарын үстерә, мөстәкыйльлекне арттыра.

Мәктәпкәче яшьтәге яңа белемнәр уен барышында унышлырак узләштерелә. Балалар алдына куелган белем биру бурычынын уен формасында бирелеше зур остенлеккә ия, чөнки уен барышында яңа белемнәр һәм эшчәнлек ысулларын үзләштерү зарурлыгы бала өчен инде анлаешлы.

Үстерешле уеннар нәниләрнен төрле яктан үсуен тәэмин итә, иҗади мөмкинлекләрен, хыялларын баетуда, фикер активлыгы һәм зиһеннәрен устерудә ныклы этергеч булып тора.

“Бергәләп уйнап алыйк” җыентыгы күпфункцияле дидактик кулланмаларны тасвирлый һәм аларны уенда һәм ситуацияләрдә куллану вариантларын ачыклап күрсәтә.

Методик кулланма мәктәпкәчә белем биру учреждениyaләрнең тәрбиячеләре һәм өлкән тәрбиячеләре өчен тәкъдим ителә.

**Дидактик кулланма “Әкияти шакмаклар”**



**Автор**: муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе– Теләченең №2 балалар бакчасының 1 квалификацион категорияле тәрбиячесе Гайбадуллина Миләүшә Фәнис кызы

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда режим моментларында, уен эшчәнлеге барышында ана (татар) телендә бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгыту.

**Бурычлар**:

- Татар халык әкиятләре аша балаларда туган (татар) теленә, татар халык авыз иҗатына кызыксыну уяту.

- Балаларга “Әкияти шакмаклардан” таныш әкиятне танып, аның сюжетын эзлекле рәвештә төзеп, эчтәлеген бәйләнешле итеп сөйли белүләренә ирешү.

-Балаларның игьтибарлыкларын, хәтерләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү.

-Татар әкиятләре буенча белемнәрен ныгыту.

**Материал**: йомшак губкадан ясалган һәм материал белән тышланып тегелгән шакмаклар. Шакмакның һәр ягына татар халык әкиятләре буенча сюжетлы рәсемнәр ябыштырылган.

**Дидактик кулланма “Әкияти шакмаклар”лар уйнау тәртибе**

**Дидактик уен “Әкиятне таны һәм эчтәлеген сөйлә!”**

Бу уенны бер яисә берничә бала уйный ала. Уенчыга яки уенчыларга татар халык әкиятләре төшкән рәсемле шакмаклар бирелә. Бала таныш

булган бер әкиятне сайлап, аның сюжетын шакмаклар ярдәмендә төзеп бәйләнешле итеп эчтәлеген сөйәргә тиеш.

 

**Дидактик уен “Әкият геройларын таны”**

Бу уенны берничә бала уйный. Уенчылар берәр шакмакны сайлап алырга һәм шакмактагы  сурәтләнгән әкият героен һәм әкият исемен атарга тиеш.

**Дидактик уен “Рәсем буенча сорауларга җавап бир!”**

Уенчыга бер шакмак бирелә. Аңа шакмакта сурәтләнгән әкият сюжеты буенча сораулар бирелә. Мәсәлән: Син бу рәсемдә нәрсәләр күрәсен? Әкият геройлары нишли?  Әкиятнең дәвамы ничек була? Бу сюжет кайсы әкияттән? Һ.б.

**Көтелгән нәтиҗә:**

“Әкияти шакмаклар” дидактик уены балаларга:

- әкият эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә,
- әкиятнең  эчтәлеген сөйләргә;
- ана (татар) телендә бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерергә,
- сүзлек запасын баетырга,
- авазларны дөрес әйтергә,
- уй-фикерләрен әйтә белергә,
- эмоциональ, сәнгатьле итеп сөйләргә,
- туган телләренә, татар халкының гореф-гадәтләренә хөрмәт  хисе тәрбияли;

**Кулланылган әдәбият:**

1. З.М. Зарипова, Л.Н., Вәҗиева, И.Ж., Р.С.Зөфәрова Туган телдә сөйләшәбез. 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. -Казан. ФОЛИАНТ, 2012.-304 б.

2. Закирова К.В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләре өчен хрестоматия.-Казан: РИЦ, 2011.-560 б.

## Методик кулланма “Серле теремкәй”

(3-7 яшьлек балалар өчен)

**Автор**: муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе– Теләченең №2 балалар бакчасының 1 квалификацион категорияле тәрбиячесе Йосыпова Гөлсинә Фәүхетдин кызы

<table>
<tr>
<td></td>
<td rowspan="2">Максат: балаларның өлкәннәр һәм үз яшьтәшләре белән туган (татар) телендә ирекле аралашуларына ирешү.<br>Бурычлар: 1. Балаларның төсләр, геометрик фигуралар, йорт һәм кыргый хайваннар турындагы күзаллавын ныгыту.<br>2. Сүз байлыгын үстерү, куелган сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирергә өйрәтү.<br>3. Бергәләп уйнау теләге тәрбияләү.<br>Җиһазлау: 1. Биремнәр җыелмасы<br>2. Фетрдан ясалган теремкәй</td>
</tr>
<tr>
<td></td>
</tr>
</table>

**Уенның барышы:** Тәрбияче биремнәр язылган конвертны алдан теремкәй эченә яшереп куя, бер бала ул конвертны ала. Тәрбияче башта биремне балаларга аңлата, рәсемнәр буенча әңгәмә алып бара, җавапларны тыңлый, аннан соң балалар биремнәрне бергәләшеп мөстәкыйль үтиләр. Уен азагында биремнәрнең үтәлешенең дөреслеге тикшерелә.

**Уен нәтиҗәләре:** Дидактик уен балалада туган телне өйрәнүгә уңай караш уята, аның уйлау эшчәнлеген яхшырта, үткән материалны ныгытырга ярдәм итә.

**Уен вариантлары.**

**Дидактик уен “Минем гаиләм”**

**Бурычлар:**

1) балаларны гаилә әгъзалары булган сюжетлы кечкенә рәсемнәрне карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү; сөйләмдә ягымлы сүзләрне (әти- әтием, әни - әнием, әби -әбием, сеңел -сеңлем) кулланырга өйрәтү; [ә] авазының әйтелешен ныгыту, аны ачык, тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүләренә ирешү;

2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү; зурлар һәм үз яшьтәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү

3) гаилә әгъзаларын ярату, һәм өлкәннәр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү, алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

**Дидактик уен “Транспорт төрләре”**

**Бурычлар:**

1) балаларны транспорт төрләрен һәм аларның өлешләрен танырга, исемен әйтергә өйрәтү; уенның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру;

2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, уңай эмоцияләрен үстерү;

3) балаларда транспорт төрләренә, өлкәннәр хезмәтенә карата кызыксыну уяту.

**Уен барышы:**

Тәрбияче атаган транспорт төрләрен ул кушкан тәрәзә эченә яшерү.Бирелгән биремнәрне үтәү.

**Дидактик уен “Җөмлә төзе!”**

**Бурычлар:**

1) рәсемдәге предметларга карап җөмлә төзеп әйтә белергә, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;

2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләренә ирешү;

3) рәсемне кызыксынып карау теләге тәрбияләү.

**Дидактик уен “Төсен яки формасын әйт!”**

**Бурычлар:**

1) балаларның җиләк-җимешләр яки яшелчәләр турындагы белемнәрен ныгыту; аларның форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, шар формасында; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер, овал формасында) белән таныштыру;

2) балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;

3) зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү

**Дидактик уен “Ел фасыллары” яки “Тәүлекнең кайсы вакыты?”**

**Бурычлар:**

1) балаларның тәүлекнең кайсы вакыты, ел фасыллары (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме) турында гади күзаллауларын формалаштыру;

2) балаларның сүз байлыгын, күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене

тыңлый белү осталыгын үстерү;

3) табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләү.

**Дидактик уен “Хайваннар һәм аларның балалары”**

**Бурычлар:**

1) балаларның төсләр турындагы күзаллавын ныгыту, җәнлекләрнең,балаларының, йорт хайваннарының, кошларының нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачыклау; ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый фигыльләрен сөйләмдә активлаштыру; авыз аша һаваны әкрен, салмак кына чыгарырга өйрәтү;

2) балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү;

3) хайваннар белән кызыксындыру, аларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.

**Дидактик уен “Урманда”**

**Бурычлар:**

1) балаларның олылар белән аралашу теләген хуплау, исем һәм сыйфатларны кулланырга өйрәтү: йомшак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре; кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына

сүзлекне активлаштыру (төлке бара, куян сикерә, аю алпан-тилпән йөри һ.б.);

2) ишетү игътибарын, координацияне, ритм хисен үстерү;

3) кыргый хайваннарга карата кызыксыну тәрбияләү.

**Дидактик уен “Йорт җиһазлары”**

**Бурычлар:**

1) балаларны өй җиһазларын таный һәм атый белергә өйрәтү, бүлмәләрдә ориентлашу тәҗрибәсе туплау;өстәл, урындык, карават, шкаф, көзге кебек исемнәр хисабына сүзлек не активлаштыру, сөйләмнең грамматик төзелешен

камилләштерү;

2) балаларның эмоциональлеген, кызыксынуларын үстерү, җиһазларга сакчыл караш тәрбияләү.

**Дидактик уен “Юыну бүлмәсендәге предметлар”**

**Бурычлар:**

1) балаларны юыну бүлмәсендәге предметлар (сабын, сөлге, кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән таныштыру, функциональ билгеләнешләре турындагы күзаллауларын ачыклау;
2) сүзләрне төрле грамматик формаларда (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.) куллану осталыгына ирешү, балаларның сөйләм активлыгын, инициативасын үстерү;
3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү омтылышы тәрбияләү.

**Дидактик уен “Бакчада нәрсәләр үсә?”**

**Бурычлар:**

1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне һәм яшелчәләрне аерырга, түтәлдә яки агачта үсүләрен истә калдырырга, аларның уңышын җыеп алу турындагы күзаллауларын киңәйтү, аларның исемнәре һәм аларның билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;
2) балаларның игътибарын, кабул итү һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;
3) балаларда әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләү.

**Дидактик уен “Дөрес киендер!”**

**Бурычлар:**

1) балаларның ел фасылларына карап киенү турындагы белемнәренә төгәллек кертү; урамга чыкканда киенү эзлеклелеген һәм киемнәрне истә калдыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;
2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүз байлыгын үстерү;
3) башкаларга ярдәм итү теләге булдыру, киемнәргә сак караш тәрбияләү.

**Дидактик уен “Әкият геройлары”**

**Бурычлар:**

1) әкияттәге геройларны атау, кайсы әкияттән булуын истә калдырырга ярдәм итү, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда куллана белергә өйрәтү, сорауны белдерә торган сүзләрне кулланырга күнектерү;
2) игътибарны, кабул итү, логик фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү;
3) бер-береңә карата игътибарлылык тәрбияләү.

**Дидактик уен Тылсымлы фигуралар”**

**Максат:** балаларның уйлау, фикерләү сәләтен үстерү. Балаларны булган геометрик фигуралардан төрле әйберләр ясарга өйрәтү.Рәсем ясау алымнарын ныгыту.

**Уен барышы:** Карточкаларда геометрик фигуралар төшерелгән, ләкин алар төрле зурлыкта. Фигураларның нинди әйбергә охшаганлыгын белеп, кирәкле өлешләрен ясарга һәм буярга.

**Дидактик уен “Уңайлы өй”**

**Максат:**Төрле әйберләрне көндәлек тормышта кулланылышы буенча төркемнәргә берләштерергә һәм ул төркемнәрне гомумиләштерүче сүзләр белән әйтергә (транспорт, савыт – саба, киемнәр, йорт җиһазлары, ашамлыклар, әкият геройлары, хайваннар, йорт кошлары, гаилә әгъзалары, җиләк-җимешләр, яшелчәләр ) өйрәтү.

**Уен барышы:**

Тәрбияче атаган предметларны тәрбияче төсләре, әкият геройлары яки саннар буенча әйткән тәрәзә эченә качыру, кую.

**Дидактик уен “Санарга өйрәнәбез”**

**Бурычлар:**

1) 1- 10 кадәр саннарны санау тәртибе буенча һәм кирегә русча һәм татарча санау күнекмәләрен камилләштер.Төрле үзенчәлекләре буенча предметларны төркемнәргә бүлү, кимрәк, күберәк сүзләрен аңлап эшләү, тигезли белү күнекмәләрен үстерү.
2) балаларда мөстәкыйльлек, кызыксыну тәрбияләү, игътибарны, кабул итү, фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү;
3) бер-береңә карата игътибарлылык тәрбияләү.

**Дидактик уен “Туган көн”**

**Бурычлар:**

1) аерым авазларның сүзләрдә һәм сөйләмдә дөрес әйтелешен ныгыту, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтү, савыт-сабаларны, ашамлыкларны белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрне (савыт-саба) аңлый һәм куллана белүләренә ирешү, җөмләләр белән җавап бирергә күнектерүне дәвам итү;
2) инициативалы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерү, башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудыру;
3) үзара аралашуга омтылыш тәрбияләү

**“Шундый ук предметны тап”**

**Бурычлар:**

1) балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү; төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, төсне белдерә торган сыйфатларны

активлаштыру;

2) балаларның  кабул итү сәләтен, игътибарын, ишетү осталыгын үстерү;

3) эшчәнлектә бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү.

**“Ул кайда?”**

**Бурычлар:**

1) балаларга йорт хайваннарының кайдалыгын әйтә белергә өйрәтү, кайда? кая? сорауларына җавап бирергә; сөйләмдә өстенә, артына, астына сүзләрен кулланырга өйрәтү;

2) балаларның  игътибарын, хәтерен үстерү;

3) уен белән кызыксыну тәрбияләү.


1. З.М. Зарипова, Л.Н., Вәҗиева, И.Җ., Р.С.Зөфәрова Туган телдә сөйләшәбез. 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. -Казан. ФОЛИАНТ, 2012.-304 б.

2. Закирова К.В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләре өчен хрестоматия.-Казан: РИЦ, 2011.-560 б.

3. Н.Г. Гарипова, Р.С. Әхмәтова, Ф, М. Хәсәнова Әйләнә-тирә дөнья белән анышу (зурлар төркеме): мәктәпкәчә белем бтрү оешмалары өчен методик кулланма. Казан: Татар. Кит.нәшр, 2016.-151 б.


## Дидактик уен “Бизәкнең парын тап”

(5-7 яшьлек балалар өчен)


**Автор:** муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе– Теләченең №2 балалар бакчасының 1 квалификацион категорияле тәрбиячесе Николаева Галина Николай кызы



**Максат:** татар халкының милли бизәкләре белән таныштыру.

**Бурычлар:**

- карточкадагы бизәкләрне чагыштырып карап, аларның бере-берсенә охшаганнарын таба белү күнекмәләрен камилләштерү;

-балаларны татар милли бизәкләренең исемнәрен атарга өйрәтү;

- балаларда татар халкының сәнгатенә кызыксыну уяту.

**Җиһаз:** ламировать итеп тигез өлешләргә кисеп бүленгән һәм ике ягына да төсле татар милли бизәкләре төшерелгән карточкалар комплекты.

**Уеннын кәгыйдәсе** : Бу уенда 4-5 бала катнаша ала. Балаларга татар милли орнаментлары төшкән бер комплект карточкалар өләшенә, икенче комплект өстәл уртасына таратып куела. Уенны алып баручы (тәрбияче) балаларга үзләренең карточкалардагы орнаментларны өстәлдәгеләре белән чагыштырып, аларның парларын табарга тәкъдим итә. Бала үзендәге орнаментның парын тапкач: “Миндә лалә чәчәге һәм аның парын алам”,- дип әйтә һәм лалә төшкән карточканы үзенә ала. Калган балалалар да шул рәвешле үз карточкаларындагы милли бизәкләрнең парларын җыялар. Уен шул рәвешле дәвам итә. Кайсы бала үзендәге карточкаларның парларын тизрәк таба, шул җиңүче була.

**Көтелгән нәтиҗә:**

Бу уен балаларга уен аша татар халык милли бизәкләрен танып, аларның исемнәрен дөрес әйтергә, матурлыкны күрә белергә мөмкинлек бирә.

**Кулланган әдәбият:**

1. Туган телдә сөйләшәбез: 5 – 7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә. өйрәтү буенча методик ярдәмлек / Төз.: З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева, Р.С.Зөфәрова һ.б.- Казан: ФОЛИАНТ, 2012.- 304 б.

2. Фуад Валеев «Татар халык орнаменты» Казан, 2002.

**Дидактик уен “Кызларны сыйлыйбыз”**
*(Кечкенәләр төркеме балалары өчен тәкъдим ителә)*

**Автор**: муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе– Теләченең №2 балалар бакчасының 1 квалификацион категорияле тәрбиячесе Закирова Айгөл Хөрмәтулла кызы.



**Максат:** балаларның ашамлыкларны тышкы билгеләр буенча танып-белүләрен, аларны башка предметлардан аера белүләрен,төсләрне танып-белүләрен, уйлау-фикерләү сәләтен, игътибарлылыгын, сөйләмен, кул чуклары эшчәнлеген үстерү; “Бу нәрсә? Ул нинди?” сорауларына җавап бирергә өйрәтү, сүзлек запасын баету; тирә-юньдәге кешеләргә карата мәрхәмәтлелек, мөлаемлылык хисләре тәрбияләү.

**Материал:** ашамлык һәм башка предметларның вак рәсемнәре, ике яки берничә (капкачына авызын ачкан кыз йөзе рәсеме төшерелгән) капкачлы савытлар.

**Уенның кагыйдәсе:**

Уенда 2 яки берничә бала да катнаша ала.

Өстәлгә таратылган вак рәсемнәр арасыннан ашамлык рәсемнәрен сайлап алып “кызның авызына каптырырга” кирәк.

**Уен барышы:**

Тәрбияче: Балалар, буген Алсу белән Алисәнең туган көннәре икән, әйдәгез без аларны сыйлыйбыз. Шушы рәсемнәр арасыннан ашый торган әйберләрне табып исемен һәм аның тәме, төсе нинди булуын әйтергә кирәк. Аннан соң ул әйберне кызларга ашатабыз. Мин беренче булып уенны башлап җибәрәм һәм чират буенча уенны дәвам итәбез .

-Бу алма. Ул кызыл төстә, баллы h.б...

Уен шулай дәвам итә.

Уенны берничә вариантта уйнап була.

1. ”Кем күбрәк ашата?”: уенда катнашучылар ярышып өстәлдәге рәсемнәр арасыннан ашамлыкларны аралап алып кызларга ашаталар. Соңыннан һәр баланың җыйган ашамлыкларын санап нәтиҗә чыгарыла.

2. “Кызларга яшел төстәге (кызыл, сары) ашамлыклырны гына ашат!” уенда катнашучылар өстәлгә таратылган вак рәсемнәр арасыннан яшел төстәге ашамлыкларны гына табып ашаталар. Соңыннан балалар сайлаган рәсемнәрнең дөреслеге тикшерелә.

**<u>Көтелгән нәтиҗәләр:</u>**

Балалар ашамлыкларның атамаларын әйтәләр, рәсемдәге предметларны төркемнәргә аералар,төсләрне танып-беләләр, уйлау-фикерләү сәләте, игътибарлылык арта, сөйләм телләре камилләшә, кул чуклары эшчәнлеге активлаша; сораулага тулы җавап бирә, сүзлек запасын бай; тирә-юньдәге кешеләргә карата мәрхәмәтле, мөлаем.

**<u>Кулланылган әдәбият:</u>**

1. З.М. Зарипова, Л.Н., Вәҗиева, И.Җ., Р.С.Зөфәрова Туган телдә сөйләшәбез. 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. -Казан. ФОЛИАНТ, 2012.-304 б.

**Күпфункцияле диктик –кулланма “Ковробук”**

**Автор:** муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе–Теләченең №2 балалар бакчасы тәрбиячесе Авхалова Гөлшат Илдар кызы.

**Уен өчен билгеләнгән балаларның яше**: 1-3 яшь

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда шөгыльләр, режим моментларындагы уен эшчәнлеге барышында ана (татар) телендә сүзлек запасын баету.

**Җиһаз:** А-2 форматында ковролин тукыма, фетр тукымасыннан ясалган уен өчен кирәкле предметлар. Һәрбер предметның өлеше ябыштыргыч,

каптырмалар ярдәмендә ковролинга җиңелчә беркетелә, алына ала. Ковролин уеннарның җирлеге булып тора.

**Уенның вариантлары**

**1нче дидактик уен: “Ел фасыллары”**





**Максаты:** балаларның ел фасыллары турында белемнәрен формалаштыру.

**Үстерү бурычы:** балаларның сөйләм телен, сорауларга җавап бирү осталыкларын, игътибарын, хәтерен, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү.

**Тәрбия бурычы:** балаларда табигатькә карата сакчыл караш, кайгыртучанлык, үзара дуслык хисләре тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:** балаларның ел фасылларының билгеләре турындагы белемнәрен, табигать күренешләрен һәм алар арасындагы бәйләнешләрне аңлатуы һәм һәрбер ел фасылында башкарыла торган эшләр турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү.

**Уен тәртибе:** балага ел фасылларына туры килгән предметларны дөрес сайлап алырга, атарга кирәк. Уенны тулыландырып түбәндәге өстәмә сорауларны да бирергә була:

- “Нинди ел фасылын күрәсең?
- “Яз көне нинди үзгәрешләр була?”(җәй, көз, кыш)
- “Сиңа нинди ел фасылы ошый? Ни өчен?

**2 нче дидактик уен: “Милли бизәк”**





**Максат:** татар халык милли бизәкләре белән таныштыру

**Үстерү бурычы**: балаларда игътибарлылыкны, хәтерне, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү.

**Белем бирү бурычы:** сүз байлыгын арттыру, төсләрнең атамаларын өйрәтү.

**Тәрбия бурычы**: балаларда татар халкының милли мирасына хөрмәт тәрбияләү

**Уен тәртибе:** уенда берничә бала катнаша ала, уенчылар ковробукны үзләре теләгәнчә яки бер төстәге бизәкләрне табып бизиләр.

**Знче дидактик уен "Әкият сөйлим, тыңлагыз!"**



**Максат:** балаларны татар һәм рус әкиятләре белән таныштыру

**Үстерү бурычы:** балаларның кызыксынучанлыгын, игътибарлылыгын үстерү.

**Белем бирү бурычы:** әкиятләрне тирәнтен өйрәтү, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү, кул чуклары хәрәкәтен активлаштыру.

**Тәрбияви бурыч:** балаларда татар һәм рус әкиятләренә карата хөрмәт тәрбияләү.

**Уен тәртибе:** тәрбияче балаларга әкият сөйли, балалар фетрдан ясалган геройларны дөрес сайлап алып, нинди әкияттән, кайсы ел фасылында булуларын искә төшереп, әкиятнең эчтәлеге буенча урнаштыралар.

**Көтелгән нәтиҗә:**

Күпфункцияле диктик –кулланма "Ковробук" ярдәмендә балаларның ана (татар) телендә сөйләмнәре сүзлек белән баетыла, алар татар халык

милли бизәкләре белән танышу аша төсләрнең атамаларын истә калдыралар, мөстәкыйль уен күнекмәләре формалаштыралар; бармак чукларын камилләштерәләр үстерү, танып-белү эшчәнлеге аша ел фасыллары белән танышалар.

**Кулланылган әдәбият**


1. Ф.В. Хәзрәтова, З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (беренче кече яшьтәгеләр төркеме): тәрбиячеләр өчен методик кулланма. - Казан. Татар. Кит. Нәшр., 2012.-191 б.
2. Закирова К.В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләре өчен хрестоматия.-Казан: РИЦ, 2011.-560 б.
3. Кашапова М.Ф. Уйныйк әле, балалар. Беренче китап.-Казан:”Школа” Редакция-нәшрият үзәге, 2017.-272 б.


**Лэпбук «Тылсымлы китап»**




**Автор:** муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе–Теләченең №2 балалар бакчасының 1 квалификацион категорияле тәрбиячесе Гайнуллина Миләүшә Вәлиәхмәт кызы

**Исеме:** лэпбук “Тылсымлы китап”

**Уен өчен билгеләнгән балаларның яше**: 3-7 яшь

**Актуальлеге:** балалар бакчасында ике телдә (ана (татар), рус) белем һәм тәрбия бирү - мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендәге иң актуаль бурычларның берсе. Аралашу чарасы буларак ике телне дә яхшы белү - ул киләчәктә уңышлы уку өчен генә түгел, ә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның интеллектуаль һәм әхлакый үсеше өчен дә кирәк.

**Максат**: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда режим моментларында, уен эшчәнлеге барышында икетеллелеккә өйрәтү буенча укыту-методик

комплектлар (УМК) нигезендә ике телдә дә бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен формалаштыру һәм ныгыту.

**Бурычлары:**

**Белем бирү:** ана (татар) һәм рус телләрендә җөмләләрне дөрес итеп төзү күнекмәсен формалаштыру; балаларга ике телдә дә үзара аралашуга этәргеч бирү, сүзлек запасын баету; балаларның татар халкының милли бизәкләре, киемнәре турында белемнәрен киңәйтү.

**Үстерешле**: хәтер, логик фикерләүне, бәйләнешле сөйләм үстерү; игътибар, күрү сәләтен, вак моториканы үстерү.

**Тәрбияви:** ике телне дә өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү; гаиләгә, өлкәннәргә, табигатькә карата мәхәббәт һәм сакчыл караш, бер-берсенә ярдәм итү теләге тәрбияләү.

**Лэпбукның элементлары:** әлеге лэпбук - 4 битле кечкенә китапчык рәвешендә куркынычсыз, аллергия тудырмый торган йомшак йон тукымадан - фетрдан эшләнгән. Битләрендәге детальләр ыргак, каптырма, төймә, ябышмаларга беркетелә, куптарып алына торган уенчыклар мамык белән тутырылган. Барлык детальләр дә матур, ачык төсләрдә, балаларның игътибарын җәлеп итә.

**Титул бите**: фетрдан аппликация - чәчәкләр һәм УМКның эмблемасы – кояш.

**Беренче бит**: фетрдан авыл ишек алды күренеше, әби белән бабай, йорт кошлары һәм йорт хайваннары, авыл өйе.
**Икенче бит**: яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы күренеше, җимеш агачлары, җиләк-җимешләр, түтәлдә яшелчәләр.

**Өченче бит**: ел фасыллары буенча 4кә бүленгән, һәр фасылның үзенчәлекле билгеләре.

**Дүртенче бит**: киенү бүлмәсе күренеше, кыз һәм малай, аларның кием-салым шкафлары, сезонлы һәм милли (татар, рус) киемнәре.

**Кагыйдәләр:** Әлеге лэпбук - мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен күп функцияле, файдалы, үзенчәлекле уенчык. Лэпбукның һәр бите билгеле бер сюжет линиясе буенча бара, аның төп герое булып бала үзе яки аның яраткан әкият персонажы булырга мөмкин.

“Тылсымлы китап” лэпбугын куллануда иң мөһиме - барысын да тотарга, ачарга, чишәргә, куптарырга, бер битеннән икенче битенә күчереп йөртергә, санарга, эзләргә кирәк. Геройлар бер-берсенә кунакка, башка

битләргә йөри ала, шуңа күрә киләсе уенда геройларны урыннар белән алыштырырга була. Барлык алына торган  детальләрне җыеп баладан барысын да үз "өйләренә" (ягъни үз битләренә) кире кайтаруын сорарга була. Әлеге йомшак китап  ата-аналарга бала белән өйдә шөгыльләнү өчен тәкъдим ителергә мөмкин.

**“Тылсымлы китап” белән уен мисаллары.**

**<u>Беренче бит.</u>**

**Дидактик уен: « Дәү әни белән дәү этидә кунакта».**
**Максат:** йорт хайваннары һәм аларның яшәү тирәлеге турында белемнәрен формалаштыру, логик фикерләүне, татар һәм рус телендә бәйләнешле сөйләм телен үстерү.





**Уен вариантлары:**

**Әңгәмә:** -  “Нинди ел фасылы күрәсең?”.

- "Нинди йорт хайваннарын күрәсең?  Алар нәрсә белән тукланалар?».
- "Нинди йорт кошларын күрәсең?

**Хикәя төзү:** “Мин Дәү әни белән дәү эти янында кунакта".

**<u>Икенче бит.</u>**

**Дидактик уен:  «Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр».**





**Максат:** яшелчә һәм җиләк-җимешнең исемнәрен ныгыту; вак моториканы үстерү; гаиләгә, өлкәннәргә, табигатькә карата мәхәббәт һәм сакчыл караш, бер-берсенә ярдәм итү теләге тәрбияләү; балаларга татар һәм рус телләрендә үзара аралашуга этәргеч бирү, сүзлек запасын баету.

**Уен вариантлары:**

**Әңгәмә:** - "Нинди ел фасылы күрәсең?".

- "Нәрсә утыртырга телисең?".
- "Нинди агачлар күрәсең?".
- "Кәрҗингә күпме алма һәм груша җыйдың?".

**Хикәя төзү:** - "Мин яшелчә бакчасында эшлим".

- "Мин дәү әнигә булышам".

**<u>Өченче бит.</u> Дидактик уен: «Ел фасыллары».**

**Максат:** ел фасылларының исемнәрен, аларның үзенчәлекләрен беркетү; хәтер, логик фикерләүне, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, табигатькә карата мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү.





**Уен вариантлары:**

**Әңгәмә:** - **"**Нинди ел фасылы күрәсең?".

- "Кыш көне (яз, җәй, көз) нинди үзгәрешләр була?".
- "Нәрсә үзгәргән? Дөресләп куй".

**Хикәя төзү:** "Син нинди ел фасылын яратасың? Ни өчен?".

**<u>Дүртенче бит.</u>**

**Дидактик уен: «Курчакларны киендер».**

  

**Максат:** сезонлы һәм милли киемнәрнең атамаларын, малайлар һәм кызлар өчен кием-салым исемнәрен ныгыту, киемнең киенү эзлеклелеген камилләштерү; вак моториканы үстерү; балаларның татар халкының милли бизәкләре, киемнәре турында белемнәрен киңәйтү.

**Уен вариантлары:**

**Әңгәмә:** - **“**Курчакларга ел фасылы буенча кием-салым сайлыйбыз”.

- “Курчакны милли костюмга киендер (татар һәм рус)”
- "Без бәйрәмгә барабыз”

**Хикәя төзү:** "Шкафларда тәртип урнаштырыйк".

**<u>Көтелгән нәтиҗә:</u>**



- ✓ мәктәпкәчә яшьтәге балаларда ике телдә дә бәйләнешле сөйләм теле үстерү;
- ✓ эшчәнлектә мөстәкыйльлек күнекмәләре формалаштыру;
- ✓ мәктәпкәчә яшьтәге балаларда вак моторика үстерү;
- ✓ балаларда танып-белү активлыгын, иҗади сәләтләрен үстерү.

**Дидактическое пособие из фетра «Времена года»**

<u>Автор: воспитатель первой квалификационной категории МБДОУ-Тюлячинского детского сада №2 Зиннатва Ильсия Наилевна</u>

Возрастная категория: дошкольники 3 – 7 лет.

Цель: Закрепление знаний детей дошкольного возраста о сезонных изменениях в природе.

Задачи игры:

1. Развивающие: развитие мелкой моторики рук, фантазии, воображения, познавательной активности, зрительного внимания, слухового восприятия, любознательности, развитие самостоятельной связной речи на родном (татарском) и русском языке с опорой на дидактический материал;

2. Обучающие: изучение, обобщение, закрепление знаний о природных явлениях, использовать в речи предлоги и описательные прилагательные, упражнять в словообразовании существительных с уменьшительно-ласкательными суффиксами, упражнять в подборе антонимов и синонимов.

3. Воспитательные: воспитание познавательного интереса к природе, окружающему миру, бережного отношения к ней, а так же аккуратности и бережного отношения к мелким деталям.

Формы работы:

1. Коллективная работа.
2. Работа в парах.
3. Индивидуальная работа.

Назначение пособия:

Данное пособие предназначено для дошкольного возраста. В игровой форме дошкольники могут получать новые знания, закреплять пройденный материал, что способствует развитию связной речи на родном (татарском) и русском языке.

Пособие выполнено из фетра с использованием пайеток. Способ крепления крупных деталей: «лента липучка». В креплении мелких деталей

применён принцип фланелеграфа. Поэтому почти все детали в данном панно съёмные, что позволяет с лёгкостью заменять их при необходимости. Также возможно дальнейшее детальное пополнение каждого панно по причине его простоты исполнения.

Данное дидактическое пособие имеет разнообразное назначение.

1. Изучение последовательности наступления времён года

- лето
- осень
- зима
- весна

2. Изучение основных признаков времён года.

- «Осенний дождик»
- «Листопад, листья жёлтые летят»
- «Снег, снежок»
- «Летняя пора»
- «Уж тает снег, бегут ручьи»

3. Игры на развитие внимания, памяти

- «Что лишнее?»
- «Что изменилось?»

4. Упражнения на развитие координации движения.

- «Влево - вправо»
- «Вверх – вниз»

5. Упражнения на изучение счёта, количества, пропорции.

- «Сосчитай-ка»
- «Угадай-ка».

Для усвоения материала и более интересного проведения развивающей игры «Времена года», можно использовать стихи и загадки на родном (татарском) и русском языке:

Уж тает снег, бегут ручьи,
В окно повеяло весною…
Засвищут скоро соловьи,
И лес оденется листвою! (А. Плещеев)

Несу я урожаи,
Поля вновь засеваю,
Птиц к югу отправляю,
Деревья раздеваю.
Но не касаюсь сосен
И елочек. Я. (Осень).

Надо мною, над тобою
Пролетел мешок с водою,
Наскочил на дальний лес,
Прохудился и исчез. (Туча)

Дел у меня немало –

Я белым одеялом
Всю землю укрываю,
В лед реки убираю,
Белю поля, дома,
Зовут меня. (Зима).

Собираем в августе

Урожай плодов.

Много людям радости

После всех трудов.

Солнце над просторными

Нивами стоит,

И подсолнух зернами

Черными набит. (С. Маршак)

Загадки  Г.Тукая:

Боз һәм кар эрде,

Сулар йөгерде;

Егълап елгалар,

Яшьләр түгелде.

Көннәр озая,

Төннәр кыскара.

Бу кайсы вакыт? —

Йә, әйтеп кара.

(Яз көне)

Ашлыклар үсте,

Башаклар пеште;

Кояш пешерә,

Тиргә төшерә.

Халык ашыга,

Китә басуга,

Урагын ура, —

Бу кайчак була?

(Җәй көне)

Кырлар буш кала,

Яңгырлар ява;

Җирләр дымлана, —

Бу кайчак була?

(Көз көне)

Һәр җир карланган,

Сулар бозланган;

Уйный җил-буран, —

Бу кайчак, туган?

(Кыш көне)

<u>Ожидаемый результат:</u>

Активизация связной речи детей, расширение словаря, совершенствование звукопроизношения, уметь обобщать, закрепление знаний о природных явлениях.

Воспитание познавательного интереса к природе, окружающему миру, бережного отношения к ней, а так же аккуратности и бережного отношения к мелким деталям.

<u>Литература:</u>

1. Н.Г. Гарипова. Әйләнә-тирә дөнья белән таныштыру (уртанчылар төркеме) : мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2017

2. Хәзрәтова, Ф.В., Шәрәфетдинова, З.Г., Хабибулина, И.З. Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (уртанчылар төркеме): тәрбиячеләр өчен методик кулланма / Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И.З. Хабибулина. – Казан: Инновацион технологияләр үзәге., 2013.- 256.

3. Изучаем русский язык: программа, методические рекомендации, диагностика. С.М.Гаффарова, Казань, 2013.

4. Артёмова, Л.В. Окружающий мир в дидактических играх дошкольников: Кн. Для воспитателей дет. сада и родителей / Л.В. Артёмова. - М.: Просвещение, 1992.

**Дидактическая игра «Одеваем  плоские куклы»**



**Автор**: воспитатель первой квалификационной категории МБДОУ-Тюлячинского детского сада №2 Хабирова Алина Равилевна

**Варианты игр.**

**1. «Оденем куклу на работу»**

**Цель**: учить детей соотносить рабочую одежду с профессией человека, называть соответствующие профессии.

**Игровые действия**: поиск нужных предметов одежды в соответствии с названной профессией.

**Оборудование игры**: на столе разложены плоскостные из фетра рабочие одежды для кукол, на круглой подставке наклеены плоскостные изображения кукол из фетра, мальчики и девочки,

**Ход игры**: педагог рассказывает детям о том, что куклы собираются на работу, каждый должен одеться в рабочий костюм. Дети могут догадаться, кем работает каждый, по картинке, которая лежит рядом с куклой. На этой картинке нарисован предмет, который необходим для работы. Дети по очереди подходят, рассматривают картинку, подбирают одежду и называют соответствующую профессию.

Затем взрослый просит детей закрыть глаза, путает предметы одежды, перекладывает картинки и т. п. Дети исправляют ошибки. Игра повторяется несколько раз.

Игра может проводиться с куклами, для которых специально сшиты разные рабочие костюмы.

**2. «Кому что нужно?»**

**Цель**: учить детей соотносить орудия труда с профессией людей; называть соответствующие профессии, предметы и их назначение.

**Игровые правила**: назвать профессию в соответствии с предметом труда, объяснить назначение предмета.

**Игровые действия**: поиск нужных предметов.

**Оборудование**: на столе у педагога разложены карточки  для труда людей разных профессий. Куклы из  фетра одетые  разных профессий (подбираются картинки и предметы соответствующих профессий).

**Ход игры**: Ребенок берет какой-либо предмет и называет его. Ребенок должен найти  куклу  и приклеить  инструмент к кукле  соответствующей профессии и сказать что делает человек той или иной профессии с этим предметом. Игра продолжается до тех пор, пока не будут названы и разложены все орудия труда. Возможно проведение игры с использованием только картинок с изображением людей определенных профессий и орудий труда.

**3. «Едем на работу»**

**Цель**: учить детей ориентироваться в пространстве комнаты, находить свое место в соответствии со зрительными ориентирами - картинками с изображением профессиональных символов. Развивать внимание, память в процессе данной игры.

**Игровые действия**: движение по комнате (изображается поездка на машине) и нахождение стула или места с соответствующей профессиональной символикой (картинкой).

**Оборудование игры**: на столе у педагога разложены «рули», дети выбирают себе профессию, в разных местах комнаты стоят стулья, на них лежат картинки, изображающие инструменты.

**Ход игры**: педагог приглашает детей к своему столу, каждый может выбрать себе профессию, взять руль и поехать на работу, для этого нужно внимательно смотреть на стулья и выбирать картинку с инструментом, подходящим для этой работы. Игра проводится несколько раз, педагог перекладывает картинки на стульях, дети должны снова найти свое место. Затем дети меняются профессиями, и игра повторяется.

**4. «Собираемся на работу»**

**Цель**: учить детей подбирать инструменты для людей разных профессий. Уточнять, закреплять знания детей о труде взрослых, использовать эти знания в процессе сюжетно-ролевых игр.

**Игровые действия**: поиск нужных инструментов, складывание их в чемоданчики, стоящие рядом с куклами в рабочих костюмах.

**Оборудование игры**: куклы в рабочей одежде, чемоданчики (объемные или плоскостные с прорезями для картинок), наборы игрушечных инструментов или наборы картинок с изображением инструментов.

**Ход игры**: на столе разложены игрушечные инструменты, педагог просит собрать кукол на работу. Подбирать игрушки или картинки надо, посмотрев на рабочую одежду.

**5. Рассказы детей о профессиях и предметах, которые им нужны в работе.**

**6 «Подберем куклам одежду»**

**Цель:** Учить называть предметы одежды, дифференцировать одежду для мальчиков и девочек, последовательно одевать куклу.

**Ход игры.**

Педагог. Ребята, куклы собираются в гости, но они никак не могут одеться, так как перепутали свою одежду и не могут найти свои вещи. Давайте поможем им разобраться, где чьи вещи.

Далее педагог предлагает детям выделить заранее подготовленную одежду мальчика и для девочки.

После того как дети выберут для кукол, один ребенок начинает одевать.

**7. «Оденем куклу по сезону»**

**Цель.** Формировать навыки последовательных действий одевания на прогулку.

Продолжать учить детей запоминать и называть предметы сезонной одежды, знать ее название.

Воспитывать аккуратность, бережное отношение к одежде; желание заботиться о кукле.

**Ход игры.**

Воспитатель сообщает детям о том, что куклы уже позавтракали и хотят гулять. Подводит детей к выводу: «Надо одеть на прогулку».

Воспитатель: На улице холодно. Куклу надо одеть тепло. Какую одежду надо надеть на куклу? (Теплую)

Показ и рассматривание одежды.

Педагог показывает детям предметы одежды, называет из, рассказывает о цвете, обращает внимание на детали одежды (карманы, рукава, воротник

**8. «Угадай, какое это время года?»**

**Цель:**

- знать времена года и называть их в определенной последовательности;

-находить, соответствующие данному времени года картинки;

- оживлять композицию фигурными карточками;

- развивать зрительную память, внимание, речь;

- любить природу в разное время года.

**Ход игры:**

Воспитатель называет определенное время года. Дети должны выбирать и соответствующею картинку данному времени года, которую назвала воспитательница.



**9. «Наряжаем кукол в национальные костюмы»**

**Цель.**

Приобщить детей к знанию национальных костюмов разных национальностей.

Закрепить знания об особенностях национального костюма и его элементах.

Учить детей находить сходство и отличие костюма с другой национальной одеждой.

**Ход игры:** Детям предлагается одеть кукол в разные национальные костюмы. Предложить найти сходство и отличие между костюмами.

Обратить внимание детей на детали элементов одежды.

**10. «Модное шоу»**

Игра направлена на развитие чувства вкуса с детских лет, воспитание уверенности в себе. Ребенок по своему желанию и умению одевает куклу, подбирая подходящие к костюму головной убор, обувь и т.д. и рассказывает о ней. Поощряется умелый подпор одежды и аксессуаров к ней. Дети крутят табло и показывают друг – другу своих кукол.

**11. Рассказы детей про одежду, про орнаменты, которые изображены на ней, про праздники на которые их надевают.**

**Три цветка**

Дидактическая игра на определение характера музыки.

**Автор**: музыкальный руководитель высшей квалификационной категории МБДОУ-Тюлячинского детского сада №2 Зайнутдинова Зиля Зарифовна

**Возрастная категория**: дошкольники 3 – 5 лет.

**Цель**: определение характера музыки

**Задачи:** развитие слуха; развитие воображения; различие характерных особенностей произведения.

**Игровой материал**

**Демонстрационный:** три цветка из картона (в середине цветка нарисовано «лицо» -Спящее, плачущее или весёлое), изображающих три типа характера музыки:

1. Добрая, ласковая, убаюкивающая (колыбельная)
2. Грустная, жалобная.
3. Весёлая, радостная, плясовая, задорная.

Можно изготовить не цветы, а три солнышка, три тучки и т.д.

**Раздаточный:** у каждого ребёнка- один цветок, отражающий характер музыки.

ХОД ИГРЫ

1 вариант. Музыкальный руководитель исполняет произведение. Вызванный ребёнок берёт цветок, соответствующий характеру музыки, и показывает его. Все дети активно участвуют в определении характера музыки. Если произведение известно детям, то вызванный ребёнок говорит его название и имя композитора.

2 вариант. Перед каждым ребёнком лежит один из трёх цветков. Музыкальный руководитель исполняет произведение, и дети, чьи цветы соответствуют характеру музыки, поднимают их.